# ДӨНЬЯГА ТАНЫЛГАН АКАДЕМИК



Халыкара фәнни конференцияләрдә инглиз, гарәп, рус, немец телләрендә тирән эчтәлекле докладлар белән чыгыш ясаган татар галимнәре күп түгел. Ә менә Россия Мәгариф академиясенең, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовның Һиндстан, Таиланд, Мисыр, Кипр, Япония, Венгрия, Германиядә, Америка Кушма Штатларында төрле телләрдә ясаган чыгышларын бик теләп тыңлыйлар. Элекке СССРда да, хәзерге Россия Федерациясендә дә Мирза Исмәгыйлевичны фәнни-педагогик җәмәгатьчелек, мөгаллимнәр даирәсе олуг педагог, галим буларак нык ихтирам итә.

М.Мәхмүтов язган китаплар, сүзлекләр, төрле гыйльми җыентыкларда, газета-журналлар-да дөнья күргән саллы-саллы, зур-зур мәкаләләре генә дә 530 дан артып киткән. Боларга өстәп русча, гарәпчәдән татар теленә тәрҗемә иткән берничә китабы, аның фәнни редакторлыгында чыккан 21 зур фәнни хезмәт булуын да әйтергә кирәктер. Бер генә мисал: моннан берничә ел элек язучы Рабит Батулла, төрле галимнәр тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып, Коръәннең татарчага тәрҗемәсен матбугатка әзерләгән иде. Бу изге китап та академик Мирза Исмәгыйлевич мөхәррирлегендә дөнья күрде. Ул Коръәннең, аның сүрәләре, аятьләренең гарәпчә, татарча текстларын, мәгънәләрен тикшереп чыга... М.И.Мәхмүтов җитәкчелегендә 40 тан артык кешенең—кандидатлык диссертациясе, 10 нан артык галимнең докторлык диссертациясе яклавы да бу академикның гаҗәеп эшлекле шәхес булуы турында сөйли. (Аның үзенең дә татар педагог-галимнәреннән иң беренче академик булуын онытмыйк!) Галимнең фәнни-педагогик эшчәнлеге, гарәп теле белгече булуы хакында дөнья күргән мәкаләләр дә бихисап. Хәтта кандидатлык диссертациясе дә бар.

Бу күренекле академикның бераз гына тәрҗемәи хәленә күз салыйк. Ул 1926 елның 1 маенда Мордовиянең Ләмберә районында Алгар авылында эшче гаиләсендә туа. Җиде яшьтән ятим кала. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, тракторчылар курсында укый. Үзбәкстанның Сәмәрканд өлкәсендә механизатор булып эшли. 1944 елда армия сафына алына, хәрби мәктәпләрдә — механик, аннары хәрби авиация техникы һөнәрен үзләштерә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыш тәмамлангач, 12 ел буена хәрби частьләрдә хезмәт итә, шул чорда кичке эшче-яшьләр урта мәктәбен дә тәмамлый, читтән торып укып, Мәскәүнең бер югары уку йортында немец телен өйрәнә. 1950 — 1955 елларда Совет Армиясенең Чит телләр хәрби институтында тыңлаучы була. Гарәп һәм инглиз телләре тәрҗемәчесе-рефе-ренты белгечлеге ала, хәрби хезмәтен Рига шәһәрендә дәвам иттерә.

1956 елда Казанга килә, КДУда гарәп һәм татар телләрен укыта башлый. Фәнни эшләр белән дә шөгыльләнә. 1958 елда утыз ике яшендә аны Татарстан мәгариф министры итеп билгелиләр. 1976 елга кадәр шушы вазифаны башкара, үзен гаҗәеп оста җитәкче, булдыклы шәхес, зур галим итеп таныта. Аның «Гарәпчә-та-тарча-русча алынмалар сүзлеге» (1963), «Мәктәпләр өчен русча-татарча сүзлек» (1967, 1975, 1991) һ. б. китаплары дөнья күрә. Татар теле белеме буенча—кандидатлык (1966), педагогика буенча докторлык (1972) диссертацияләре яклый.

Министр булып эшләвенең беренче елларында ук укыту теориясендәге яңа юнәлешне — укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү буенча республикада фәнни-тикшеренү эшләрен башлап җибәрә, бу җәһәттән Мәскәү галимнәрен дә җәлеп итә. Алдынгы мөгаллимнәрнең тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм пропагандалау эшен киң җәелдерә. Үзе дә «Укучыларда мөстәкыйльлек тәрбияләү» дигән китап (1964) язып чыгара. Республика укытучылары фәнни, иҗади эштә катнаша башлыйлар, алар, укытуны индивидуальләштерү, программалашты-рылган укыту теорияләре белән тирәнтен танышып, эшкә яңача якын киләләр, яңа дидактик система буларак проблемалы укыту тәгълиматын өйрәнәләр, аның төп идеяләрен эштә кулланалар һәм җитди уңышка ирешәләр. Казанда СССР Педагогия фәннәре академиясенең проблемалы укыту буенча

дидактик лабораториясе ачыла, күптөрле фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелә. Аларда илнең күренекле педагог-галимнәре дә катнаша. Боларның һәммәсе дә министр М.И.Мәхмутов җитәкчелегендә оештырыла. 1972 елда «Проблемалы укыту теориясе һәм практикасы» дигән китабында М. И. Мәхмүтов яңа дидактик системаның асылын, төп мәгънәсен һәм аны гамәлгә ашыру ысулларын ачып бирә. Илнең төрле төбәкләрендә дә бу системадан уңышлы файдаланалар. Безнең тәҗрибәне чит илләрдән килеп өйрәнүчеләр дә арта бара. Министр китаплар язу эшен дә дәвам иттерә. Ул хезмәтләрне исә чит ил халыклары да, тәрҗемә итеп, үз телләрендә бастырып чыгаралар. Ул — ЮНЕСКО, Бөтендөнья Тынычлык Советы әгъзасы буларак та актив эшләгән шәхес. Гомумән, тынгысыз галим, эшне оста оештыра белә торган кеше ул Мирза Исмәгыйлевич, Казанда Россия Мәгариф академиясенең Махсус -урта белем бирү институтын (17 ел буена аның директоры булды), Татар-Америка региональ институтын оештырды.

1996 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең иҗтимагый-икътисадый фәннәр бүлегенең академик-сәркәтибе вазифасын башкара. Соңгы берничә елда аның җитәкчелегендә һәм автордашлыгында бу бүлек берничә китап бастырып чыгарды. Һәммәсе дә бик мөһим мәсьәләләргә багышланган. Үзенең сиксән яше тулар алдыннан академик М. И. Мәхмүтов гаҗәеп җитди һәм бик зур хезмәтен — «Мир ислама» дигән китабын төгәлләде.

Фәрит ШӘРИФУЛЛИН,
Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган укытучысы.

Редакциядән:

Без Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Дәүләт бүләге лауреаты академик Мирза Исмәгыйлевичны 80 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.